**Республика Татарстан**
**Исполнительный комитет**
**Дуртмунчинского сельского**
**поселения Заинского**
**муниципального района**

ул. Молодежная, д. 148, с. Дурт-Мунча,
Заинский район, (423515)
Тел. 6-03-10

**Татарстан Республикасы**
**Зәй муниципаль районы**
**Дурт-Мунча авыл җирлеге**
**башкарма комитеты**

Яшьләр урамы, 148 нче йорт, Дурт-
Мунча авылы, Зәй районы,
тел. 6-03-10

Телефон, факс 6-03-10. Электронный адрес: Durt.Zai@tatar.ru, сайт: www.durtmuncha.ucoz.ru


**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**№ 10** **10.04.2025 ел**

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Дүрт-Мунча авыл җирлеге территориясендә йорт хайваннарын йөртү урыннарын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль Закон, «Хайваннар белән җаваплы эш итү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 27 декабрендәге 489-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Дүрт-Мунча авыл җирлеге Советының 24.12.2018 елгы 140 номерлы карары нигезендә «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Дүрт-Мунча авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында», Зәй муниципаль районының Дүрт-Мунча авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Дүрт-Мунча авыл җирлеге башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Дүрт-Мунча авыл җирлеге территориясендә йорт хайваннарын йөртү өчен, күрү сәләте буенча инвалидны озата йөрүче юл күрсәтүче эттән тыш, түбәндәге урыннарны билгеләргә:

- файдаланудагы яисә хуҗа милкендәге җир кишәрлекләре;
- халык күп җыелмый торган авыл җирлеге территориясендә бушлыклар, торак сектор һәм җәмәгать урыннары артындагы урыннар, борындыкларда һәм тезгеннәрдә аларның хуҗалары күзәтүе астында:
- Дүрт-Мунча авылының көньяк-көнчыгыш өлешендә Яшьләр урамыннан 120 метр ераклыкта, (координатлар 55.432182, 52.317996), кадастр номеры 16:19:050203:211;
- Кабан-Бастрык авылының көньяк өлешендә Биш-Балта урамыннан 60 метр ераклыкта (координатлар 55.408835, 52.325988), кадастр номеры 16:19:050104:24;
- Зычебаш авылының көньяк өлеше Үзәк урамнан 120 метр ераклыкта (координатлары 55.453608, 52.337235), кадастр номеры 16:19:050304:33.

Әлеге пунктның тәэсире эт йөртүчеләргә кагылмый.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (PRAVO.TATARSTAN.RU), җирлекнең торак пунктлары территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре»бүлегендә урнаштырырга.

4. Контроль за исполнением настоящего постановления оставляю за собой.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Р.Т.Ситдиков**